| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ ПЕТРОВСКО-ЗАВОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ПЕТРОВСКИЙ ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

“07” ноябрь 2024 ел №10

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 13 ноябрендәге 16 номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 13 ноябрендәге 16 номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктта түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) 1,2% түбәндәгеләргә карата:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән 1000 квадрат метрдан артык гомуми мәйданы булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар).».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән алып 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга .

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Р.Нуртдинов